# *Яшәп булмый никтер салмак кына...*



**Рәкит Яүдәт улы Әбделманов (Рәкит Аллабирде) 1960 елның 22 мартында Башкортстан Республикасының Күмертау районы Яңа Аллабирде авылында туган. Хәрби диңгез флотында хезмәт иткәннән соң, 1983 елда Татарстанга, КАМАЗга эшкә килә.**

**Бала чактан әдәбияткә гашыйк Рәкитнең каләм тибрәндерә башлавына укытучы әнисе, җор телле әтисе этәргеч булса, чын-чынлап иҗат эшенә бирелүенә сөекле хатыны Гөлчирә сәбәпчедер, бәлки...**

**1988 елдан "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсе белән тыгыз элемтәдәге Рәкитнең шигырь һәм хикәяләре республиканың вакытлы матбугатында күренә башлый. 1996 елда туган як хатирәләре, хикәя һәм шигырьләр тупланган "Аллабирде" исемле беренче китабы дөнья күрә.**

**1997 елдан — "Идел-Урал" хәйрия фонды җитәкчесе.**

**2009 ел нәтиҗәләре буенча "Алтын йөрәкле кеше" һәм "Татарстан Республикасы хәйриячесе"дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.**

**2010 елда "Яр Чаллы шәһәре алдындагы казанышлары өчен" медале белән бүләкләнде.**

## АЛИҺӘМӘ

*Нур-очкыннан туган карашың*
*Сискәндерде йөрәк ярасын!*
*Бу мизгелнең сихри эзләрен*
*Гомер буе, ахры, эзләрмен...*

Их, язмышым... Әле генә, хәрби диңгездә хезмәт итеп, зур өметләр белән сиңа ияреп КАМАЗ заводларына килгән һәм флоттагы һөнәре белән ашкынып эшли башлаган эчкерсез-хыялый Башкортстан егетен һәлакәткә тапшырып, аяксыз калдырдың...

Гомер буе нужа куган, фидакарь эшче нәселнең бер баласы, кичке укуга кереп, аң-белемле зур тормышка таба ныклы адымнар белән юл алган иде...

Шәһәрнең җыелма командасына алынып, волейбол буенча үрләр яуларга омтылган типсә тимер өзәрдәй егетне, бер командада иңгә-иң терәп көрәшкән хирург дустының хафаланудан калтыранган скальпеле аша спорттан мәңгегә аерырга теләдең...

Моңга гашыйк, гармунчы, очып-очынып биергә яратучы егетнең күңелендә өерелгән ташкын хисләрен томаларга, ихтыярын басарга булдың бугай...

Бүлмәдәшләре шау-гөр килеп эшкә җыенганда, тулай торакның тынчу-кысан почмагында авыр уйлары белән янәшә калдырдың. Эш-тияреннән мәхрүм итеп, мохтаҗлыкка дучар итгең...

Иптәшләре шаярткалаган булсалар да, карашларында шөбһәшик бар: "Үз-үзенә кул салмаса ярар иде..."

Аһ, язмышым... Матур яз аенда, аяз-кояшлы тормыш күгеннән бөтереп, дөм караңгы тормыш төбенә, гарип-горәбәләр дөньясына ташладың. Аһ-зарлы голәмәдә, тирә-юньгә моң чәчрәтеп бәреп торган дәрт чишмәсе кибәр, ихтыяр-кодрәте сүнәр, сиңа буйсыныр дип инандың...

Тик син ялгыштың!

Минем янда тагын бер изге җан барын белмәдең.

Белә дә алмыйсың — аның үз язмышы. Мин аңа кушылам.

Чөнки минем —

*Тереклеккә юл-күперләр*
*саласым бар.*
*Кешелеккә шул юллардан*
*атлыйсым бар.*
*Мохтаҗларны үзем белән*
*әйдисем бар.*
*Изге җанлы мәхәббәтем*
*аңлыйсым бар!*

Мин өр-яңадан аяз күккә үрәләм...

Исәнме кояш!

***

Ярсып чабам,
бала чакка, туган якка —
Хыялларда,
ак канатлы тулпар атта.
Җилеп узган,
зилзиләләр купкан якта,
Мәшәкатьләр
өерелеп кала артта.
Күңелләрдә нинди рәхәт
арынулар...
Каршы ала мөлдерәмә
сагынулар.
... Төштәме соң, өндәме соң
кабатланам.
Яшьлегемә кайткан кебек
канатланам!

## Хыял атым

*Этләр өрә, кәрван бара...*
(Әйтем)

Яшәп булмый никтер салмак кына...
Хыял-атым һаман алдан йөри.
Тукталып бер каранмакчы булам —
Язмыш әллә мине алдап йөри...

Каерылып тартам авызлыгын,
Кубарылып чапкан атым тыеп.
Тыпырчына атым, пошкырына —
Хәвеф-хәтәр янда барын тоеп.

Аерырга телим кара-акны,
Салкын җилләр нигә каршы исә?
Караңгылык чорный тирә-якны,
Этләр өрү алда юлны кисә...

...Томырыла атым, авызлыгын өзеп,
Мәңгелектән артта калмас кебек.
Суырылып чыгам тоткынлыктан —
Күңелләрем инде талмас кебек.

Этләр өргән җирдә күкрәп яшәү
Язмышларда, бәлки, сирәктер дә...
Караңгыга дагаларны бәреп,
Очкын чәчеп үтү кирәктер дә!

## Гаярьләр

Язгы кич. Торналар чылбыры
Талпына шәфәкъкә үрелеп.
Әйтерсең биләүдә һәрбер кош
Тибрәнә бер моңга төренеп.

Бер урын буш калган төркемдә
Шуңамы җырлары аяныч.
Кайдадыр баш салган, гаярь кош,
Табалмый чит җирдә таяныч.

Күңелем күзендә бу урын
Буш түгел — ап-ак эз күренә.
Нәселнең чылбырын тотышып
Кош җаны кайтамы иленә.

Ишетәм мин аваз: "Кавемем
Үз эзен сакласа һавада,
Җанымны һәркемгә бүлгәләп,
Яшәрмен гел сезнең арада".

## Чәчкә

*"Гөлчирә" — дөньяда тик бер чәчкә.*

Гөл-чәчкәләр серле күз атканда
Күбәләкләр кунып наз ала.
Шатланасың шуңа, кул чәбәкләп —
Әйтерсең лә һаман кыз-бала.

Карап торам сиңа, һушым китеп —
Фәрештәме бизи һәр көнем.
Ходай бүләгеме, могҗизамы —
Беренчедәй үтә һәр төнем!

Айный алмам бугай гомерем буе
Онытсам да шәраб исләрен.
Кичер мине, шашып сөйгән чакта
Ташып китсә әгәр хисләрем.

Ямьле язны нәкъ уртага ярып,
Тәүге аваз килгән галәмдә:
"Гөлчирә" ул — чәчкә матурлыгы,
Аңлатмаслык шигъри каләм дә!

## Чаткы

*Гөлзада ханым Рзаевага.*

Кулларымда бабамнарым рухын
Тоташтырган чаткы.
Гасырлардан караңгыга суза
Нечкә генә якты.

Ул яктыда дәверләрнең шавы
Ишетелеп кала.
Алга әйдәп, халкым җәүһәрләрен
Биштәремә сала.

Учым белән утны җилдән саклап
Үзем алдан барам.
Адым саен тирәнәя бара
Йөрәктәге ярам...

Үткәннәрне мәңгелеккә илтеп
Кушу юлын эзлим.
Адашмыйча барып җитү кирәк,
Бәлки, соңгы эз мин.